РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТҮБӘН
КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ЖИТӘКЧЕСЕ
Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел.: (8555) 42-50-50, факс: 42-42-67. E-mail: tuban.kama@tatar.ru, сайт: e-nizhnekamsk.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 803 2015 елның 8 мае

# 2015 елда Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан су объектларында кешеләрнең тормышын һәм сәламәтлеген саклау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы РФ Федераль законы, «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2009 елның 23 апрелендәге 256 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә урнашкан елгаларда, күлләрдә, сусаклагычларда һәм башка су объектларында кешеләрнең тормышын һәм сәламәтлеген саклау максатларында, **карар бирәм:**

1. Түбән Кама муниципаль районы су объектларында 2015 елга халыкның тормыш эшчәнлеге куркынычсызлыгын тәэмин итү планын расларга (кушымта).

2. Түбән Кама муниципаль районы су объектларында коену сезоны срокларын 2015 елның 1 июненнән 30 августына кадәр билгеләргә.

3. Россия Федерацияс Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм бәла-каза нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча аз үлчәмле суднолар буенча дәүләт инспекциясе үзәгенең Түбән Кама бүлекчәсенә (алга таба - ГИМС) (Бәхтиозин Т.Х.) тәкъдим итәргә:

3.1. Түбән Кама муниципаль районы территориясендә «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләрнең тормышын саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2009 елның 23 апрелендәге 256 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын гамәлгә ашыру буенча эшне оештырырга.

3.2. Су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итүне һәм халык күпләп ял итә торган урыннарда аз үлчәмле суднолар куллануны тикшереп торуны оештырырга

3.3. Су объектларындагы хәлләр турында халыкка мәгълүмат җиткерү буенча массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшне активлаштырырга. Ял һәм коену вакытында суда үзеңне тоту кагыйдәләрен вакытында җиткерергә.

3.4. Су объектларында халык күпләп ял итә торган урыннарны әзерләүдә җирле үзидарә органнарына методик ярдәм күрсәтү.

3.5. Пляжларны, аз үлчәмле суднолар өчен базаларны (стоянкаларны) җиһазлау буенча методик тәкъдимнәрне эшләргә һәм кызыксынган вазыйфаи затларга җиткерергә.

3.6. Контроль оештырырга:

- 2015 елда навигациягә йөзү һәм техник чаралар әзерләү;

- аз үлчәмле судноларны һәм аларның тукталышлары өчен базаларны (корылмаларны) техник тикшерүдә кулланыла торган таләпләрне катгый үтәү буенча;

- Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә урнашкан пляжларны, аз үлчәмле суднолар кую өчен базаларны (корылмаларны) эксплуатацияләүгә җаваплы вазыйфаи затлар белән уку җыеннары уздыру.

- Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы уку йортларында ГИМС бүлекчәләренең урнашу урыннары буенча су объектларында куркынычсыз тәртип буенча ГИМС инспекторлары составы тарафыннан профилактик эшләрне планлаштыру һәм уздыру;

- гражданнарның күпләп ял итү урыннарында бәхетсезлек очракларын кисәтү буенча профилактик эшне көчәйтергә.

4. Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Түбән Кама муниципаль районы буенча идарәсенә (Слободюк К.П) оештырырга:

4.1. Җәйге сәламәтләндерү лагерьларында балаларның ял итү урыннарындагы су объектлары төбен тикшерү эшләрен башкару, Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чикләрендә суда гадәттән тыш хәлләр барлыкка килгәндә, эзләү - коткару эшләрен уздыру буенча Зона ПСО №6 ( Садыйков Х.М ) белән хезмәттәшлек.

4.2. ГИМС үзәгенең Түбән Кама бүлеге белән берлектә 4 җәмгыять - коткару постын ачу: Кама Аланы бистәсендә, «Шинчы» базасы янындагы шәһәр пляжында, Кызыл Чишмә бистәсендә, Кама елгасындагы «ТЭЦ» базасында һәм Долгое, Ильинка һәм Карьер күлләре районындагы бер мобиль пост.

5. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетның сәүдә һәм куллануычылар хезмәтләре бүлегенә (А.Н. Родионов):

5.1. Җәйге кафе-пляжлар җитәкчеләре белән пляждан файдаланганда халыкның иминлеген тәэмин итү һәм сәүдә оештыру мәсьәләсе буенча киңәшмә үткәрергә.

5.2. ГИМС (Бәхтиозин Т.Х.) белән берлектә җәйге кафе-пляжларны техник тикшерүдә һәм эксплуатацияләү буенча рөхсәт бирүдә катнашырга.

6. Россия Эчке эшләр министрлыгының Түбән Кама районы буенча идарәсенә (Садыйков А.А.) һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Түбән Кама муниципаль районы буенча Сәламәтлек саклау идарәсенә (Хәлфиев И.Н.) пляжларның эш чорына хокук тәртибен саклауны һәм ял итүчеләргә даими медицина хезмәте күрсәтүне тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

7. Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Түбән Кама районы һәм Түбән Кама шәһәре территориаль бүлегенә (Изиятуллин Р.М.) пляжларны һәм Түбән Кама муниципаль районы гражданнарының күпләп коену һәм ял итү башка урыннарын эксплуатацияләүнең һәм карап тотуның санитар

кагыйдәләрен үтәүне контрольдә тотуны тәэмин итүне тәкъдим итәргә. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма Комитетына халыкка коену өчен яраклы муниципаль сулыклар исемлеген Түбән Кама муниципаль районы буенча Татарстан Республикасы ГТХМ идарәсе аша тәкъдим итәргә.

8. Татарстан Республикасының «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең авыл җирлекләре башлыкларына тәкъдим итәргә:

8.1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 23 апрелендәге 256 номерлы карары нигезендә суда кешеләрнең тормышын һәм сәламәтлеген саклау эшен оештыру.

8.2. Авыл җирлеге территориясендәге суда халык күпләп ял итә торган урыннарны норматив-хокукый актлар белән билгеләргә, аларны оешма һәм предприятиеләр җитәкчеләренә беркетергә, аларда пляжлар оештырырга һәм аларны билгеләнгән таләпләргә туры китереп җиһазларга.

8.3. Халыкның тормышы һәм сәламәтлеге өчен куркыныч булган урыннарда коенуга тыю билгеләү һәм моның өчен җиһазландырылмаган урыннарда коенуны булдырмау турында тыю билгеләре кую.

8.4. Җәйге чорда авыл җирлекләре хезмәткәрләре тарафыннан сулыкларны патрульлек итүне оештырырга.

8.5. 2015 елның җәйге чорында физик яктан әзерлекле, суда зыян күрүчеләргә беренче ярдәм күрсәтә белүче кешеләрдән ирекле коткару постларында дежурлык булдыру һәм оештыру буенча чаралар күрергә. Җаваплы вазыйфаи затларны билгеләргә һәм вакытлыча ирекле җәмәгать постларында дежур торышына контроль оештырырга.

8.6. Пляжларда һәм массакүләм ял итү урыннарында спиртлы эчемлекләр сатуны тыю һәм барлык төр эчемлекләрне пыяла савытларда сатуны чикләү турындагы мәсьәләне карарга.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М.А.Хәмидуллинга йөкләргә.

Т.Х. Камалетдинов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесенең
2015 елның 8 нче май
803 нче номерлы карары белән расланган
кушымта

2015 елга Түбән Кама муниципаль районы су объектларында халыкның тормыш эшчәнлеге иминлеген тәэмин итү планы

| **Максат исеме** | **Бурыч исеме** | **Чараларның исеме** | **Чараларның үтәлү вакыты** | **Җаваплы башкаручылар** |
|---|---|---|---|---|
| **1** | **2** | **3** | **4** | **5** |
| Түбән Кама муниципаль районы су объектларында халык иминлеген тәэмин итү | Коткару постларын үстерү | Пляж һәм санкцияләнмәгән халыкның суда ял итү урыннары реестрын булдыру һәм алып бару | Ел буена | Россия Федерацияс ГТХМ-ның Татарстан Республи-касы буенча аз үлчәмле суднолар буенча дәүләт инспекциясе үзәгенең Түбән Кама бүлекчәсенә (Бәхтиозин Т.Х.); Татар-стан Республикасы ГТХМ-ның Түбән Кама муници-паль районы буенча идарәсе (Слободюк К.П) |
| | | Балалар сәламәтләндерү лагерь-ларында суда кешеләрнең тормыш эшчәнлеге иминлеген тәэмин итү кагыйдәсе таләплә-рен үтәү. Сәламәтләндерү лагерьлары янындагы сулык- | Су коену сезоны буенча | Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе (Абдрахманов А. Ф.);<br>Мәгариф идарәсе (Фәретдинов А.Р.) |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | ларда балаларның коенуын тыярга | | |
| | | Әлеге сулыкларда коенуны тыю турында аншлаглар элү. Авыл җирлекләре янында урнашкан сулыкларда балалар коенуын тыю турында профилактик эш алып барырга. | | Россия Федерацияс ГТХМның Татарстан Республикасы буенча аз үлчәмле суднолар буенча дәүләт инспекциясе үзәгенең Түбән Кама бүлекчәсенә (Бәхтиозин Т.Х.); Түбән Кама районы авыл җирлекләре башлыклары |
| | | Пляжларны тикшерү һәм билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәүгә коткару постларын инвентаризацияләүне үткәрү | Апрель-май | Россия Федерацияс ГТХМның Татарстан Республикасы буенча аз үлчәмле суднолар буенча дәүләт инспекциясе үзәгенең Түбән Кама бүлекчәсенә (Бәхтиозин Т.Х.) |
| | | Суда бәхетсезлек очракларын кисәтү һәм профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау буенча күрсәтмә агитация белән тәэмин итү белән халык күпләп ял итә торган урыннарда су объектларында коткару постларын булдыру | Май - июнь | Тышкы реклама, мәгълүмат һәм төзекләндерү идарәсе; Россия Федерацияс ГТХМның Татарстан Республикасы буенча аз үлчәмле суднолар буенча дәүләт инспекциясе үзәгенең Түбән Кама бүлекчәсенә (Бәхтиозин Т.Х.) |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Эшкуарларны суда иминлекне тәэмин итү өчен кирәкле инфраструктура белән шәхси пляжлар булдыруга җәлеп итү | Май - июнь | Сәүдә һәм кулланучылар хезмәтләре күрсәтү бүлеге (Родионов А.Н.) |
| | Халыкны суда үз-үзеңне тоту кагыйдәләренә өйрәтү | Балаларның суда куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен җаваплы балалар сәламәтләндерү лагерьлары җитәкчеләрен һәм хезмәткәрләрен укыту | Ел буена | Яшьләр һәм спорт идарәсе (Абдрахманов А. Ф.)<br>Россия Федерацияс ГТХМның Татарстан Республикасы буенча аз үлчәмле суднолар буенча дәүләт инспекциясе үзәгенең Түбән Кама бүлекчәсенә (Бәхтиозин Т.Х.) |
| | | | | Суда коткару отряды «ОСВОД» (Куляев И.Н.) |
| | | Балаларны сәламәтләндерү лагерьларында суда үзеңне тоту кагыйдәләренә өйрәтү | Су коену сезоны буенча | Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе (Абдрахманов А. Ф.);<br>Россия Федерациясе ГТХМның Татарстан Республикасы буенча аз үлчәмле суднолар буенча дәүләт инспекциясе узэгенең Түбән Кама бүлекчәсенә (Бәхтиозин Т.Х.);<br>Суда коткару отряды «ОСВОД» (Куляев И.Н.) |
| | | Югары уку йортлары базасында студентларның коткару | Ел буена | Югары уку йортлары җитәкчеләре; |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | отрядларын булдыру | | Россия Федерацияс ГТХМның Татарстан Республикасы буенча аз үлчәмле судholap буенча дәүләт инспекциясе үзәгенең Түбән Кама бүлекчәсенә (Бәхтиозин Т.Х.);<br>Суда коткару отряды «ОСВОД» (Куляев И.Н.);<br>Татарстан Республикасы ГТХМның Түбән Кама муниципаль районы буенча идарәсе (Слободюк К.П) |
| | | Коткаручыларны укытуны оештыру | Ел буена | Россия Федерацияс ГТХМның Татарстан Республикасы буенча аз үлчәмле судholap буенча дәүләт инспекциясе үзәгенең Түбән Кама бүлекчәсенә (Бәхтиозин Т.Х.);<br>Суда коткару отряды «ОСВОД» (Куляев И.Н.) |
| | | Мәхәллә кешеләре арасында суда куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча аңлату эшләре үткәрү турында дини конфессияләр вәкилләре белән хезмәттәшлекне оештыру | Ел буена | Россия Федерацияс ГТХМның Татарстан Республикасы буенча аз үлчәмле судholap буенча дәүләт инспекциясе үзәгенең Түбән Кама |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | бүлекчәсенә (Бәхтиозин Т.Х.) |
| | | Хезмәт коллективларында һәм профсоюз комитетларында спорт-массакүләм һәм физкультура-сәламәтләндерү эшен яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар комплексын эшләү һәм тормышка ашыру | Ел буена | Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе (Абдрахманов А. Ф.);<br>Предприятие җитәкчеләре |
| | | Торак пунктларны үстерүнең шәһәр төзелеше планнарына яңа микрорайоннарда йөзү бассейннары төзүне мәҗбүри кертү буенча тәкъдимнәр әзерләү | Ел буена | Төзелеш һәм архитектура идарәсе (Юнысов Л. Р., Сиражетдинов Э. Р.) |
| | | Халыкның суда куркынычсызлыгы культурасын күтәрүгә юнәлдерелгән чаралар уздыру | Су коену сезоны буенча | Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе (Габдрахманов А. Ф.),<br>Мәгариф идарәсе (А.Р. Фәретдинов),<br>Россия Федерацияс ГТХМның Татарстан Республикасы буенча аз үлчәмле суднолар буенча дәүләт инспекциясе үзәгенең Түбән Кама бүлекчәсенә (Бәхтиозин Т.Х.) |
| | | Гомуми белем бирү учреждениеләрендә су спорт | Ел буена | Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе (Абдра манов А. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төрләрен үстерү, шул исәптән ярышлар уздыру | | Ф.)<br>Мәгариф идарәсе (А.Р. Фәретдинов) |
| | | «Олимпиец» балалар сәламәтләндерү лагере базасында су спорт төрләре буенча Түбән Кама шәһәре яшүсмерләр һәм яшүсмерләр җыелма командалары өчен җәйге чорда укыту-тренировка җыеннарын оештыру һәм уздыру | Июнь-август | «Олимпиец» балалар сәламәтләндерү лагере (А.С. Протасова); Яшьләр эшләре<br>һәм спорт идарәсе (Абдрахманов А. Ф.) |
| | Иҗтимагый оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү | Суда куркынычсызлыкны тәэмин итү өлкәсендә эшләүче коммерцияле булмаган иҗтимагый оешмаларга мөлкәти, консультация һәм мәгълүмати ярдәм күрсәтү буенча чаралар комплексын уздыру | Ел буена | Татарстан Республикасы ГТХМның Түбән Кама муниципаль районы буенча идарәсе (Слободюк К.П) |
| | Массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү | Суда үзеңне тоту кагыйдәләрен һәм суга баткан кешеләргә беренче медицина ярдәме күрсәтүне массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштыру | | Җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге (Камелина М. В.) |